**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге составына керүче  Норлат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

15 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Норлат авыл җирлегенең Норлат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Нрлат авылында су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау,  су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм Норлат авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2024 елның  15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә,  халык җыенында катнашучылар исемлегенә  246 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 199 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 123 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге составына керүче Норлат авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Норлат авыл җирлегенең Норлат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә –Нрлат авылында су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау,  су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм Норлат авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү өчен тотуга Сез ризамы?»  дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Норлат авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ М.Х.Закиров

Норлат авыл җирлеге
башлыгы _________________ М.Х.Закиров